# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сахаровка авыл торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**2024 елның 17 октябрендәге 2 номерлы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сахаровка авыл торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сахаровка авыл торак пункты территориясендә(торак пункт территориясенең өлеше) яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндез укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;**

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;**

**- торак пункт территориясен төзекләндерү;**

**- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;**

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Сахаровка авыл җирлегенең Сахаровка авыл мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск

муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr:/ / pravo. tatarstan .ru)бастырып чыгарырга .

Гражданнар җыенында рәислек итүче, Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегенең 1 нче сайлау округы депутаты

Н.И.Леденцов

(имза) (имзаның расшифровкасы)